Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгы

от «22» 02. 2023
№ 23 од

Татарстан Республикасы
дәүләт идарәсен цифрлы
нигездә үстерү, мәгълүмат
технологияләре һәм элемтә
министрлыгы
от «22» 02. 2023
№ п/40

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда хокукый актларны рәсми бастырып чыгарганда үзара хезмәттәшлек регламенты турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 18 маендагы 01-02/292 номерлы һәм Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 70-П номерлы уртак боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге 68-ПУ номерлы Указы чыгарылуга бәйле рәвештә, боерабыз:

«Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматларының рәсми порталында хокукый актларны рәсми бастырып чыгарганда үзара хезмәттәшлек регламенты турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 18 маендагы 01-02/292 номерлы һәм Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының  70-П номерлы уртак боерыгына (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 9 июнендәге 114од номерлы һәм Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының п/145 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында» хокукый актларны рәсми бастырып чыгарганда үзара хезмәттәшлек Регламентында, расланган боерык белән:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе актлары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе»;

2.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе актлары»;

2.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе актлары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тарафыннан җибәрелә торган Татарстан Республикасы Президенты актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе тарафыннан җибәрелә торган Татарстан Республикасы Рәисе актлары» сүзләре белән алмаштырырга;

5.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
юстиция министры — Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
дәүләт идарәсен цифрлы
нигездә үстерү, мәгълүмат
технологияләре һәм элемтә
министры — А.Р. Хәйруллин